**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Чуаш Киштәге авыл җирлеге составына керүче Новоселки торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР**

20 ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Чуаш Киштәге авыл җирлегенең Новоселки авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Новоселки авылында юлларны төзекләндерүгә юнәлтүгә Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2020 елның 20 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучы 61 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 31 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 35 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Чуаш Киштәге авыл җирлеге составына керүче Новоселки авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Чуаш Киштәге авыл җирлегенең Новоселки авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Новоселки авылында юлларны төзекләндерүгә юнәлтүгә Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Чуаш Киштәге авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Чуаш Киштәге авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: ______________ И.А.Павлов

Чуаш Киштәге авыл җирлеге
башлыгы __________________ И.А.Павлов